Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының "Иске Гришкино авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең гражданнар җыены карары

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Иске Гришкино авыл җирлеге составына керүче торак пунктта гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2020 елның 26 ноябреннән № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Иске Гришкино авыл җирлеге составына керүче торак пунктта гражданнар җыены карар итте:

1. Менделеевск муниципаль районының Иске Гришкино авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 300 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә һәм 1, 2 төркем инвалидлар, 18 яшькә кадәр тәрбиядә балалары булган күп балалы гаиләләр, көндезге формада белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүгә чакырылган гражданнар өчен бер тапкыр түләнә торган түләүне киметергә, һәм әлеге категориядәге гражданнар өчен 150 сум күләмендә билгеләргә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Иске Гришкино авылына су насосы сатып алу;
- Иске Гришкино авылындагы җирле әһәмияттәге юлларны ямау өчен вак таш сатып алу;
- Иске Гришкино авылында җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;
- Иске Гришкино авылында җирле әһәмияттәге юлларны грейдлау;
- Иске Гришкино авылында суүткәргеч объектының техник планын әзерләгән өчен түләү;
- Иске Гришкино авылында суүткәргеч объектының техник планын әзерләгән өчен түләү;
- Иске Гришкино авылының үзәк суүткәргеч коесы өчен божралар сатып алу;
- Иске Гришкино авылында үзәк суүткәргеч системасына кое урнаштыру өчен җир эшләре (копка).

Узган еллардагы үзара салымның калган өлешен Иске Гришкино авылында юлларны кардан чистартуга юнәлдерергә.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Иске Гришкино авылы мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Менделеевск муниципаль районының рәсми интернет сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгы В.В.Мамакова